**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Әлки районының Иске Үргәагар авылы;

Сарман районының Кормаш авылы;

Тәтеш районының Кече Тормы авылы;

Тукай районының Останково авылы;

Теләче районының Лесной поселогы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Аксубай районының Яңа Үзи авылындагы Адоратский урамы;

Апас районының Апас шәһәр тибындагы поселогындагы Киров урамы;

Яңа Чишмә районының Екатерина Бистәсе авылындагы Чокыр яны урамы;

Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылындагы Мәктәп урамы;

Балык Бистәсе районының Троицкий Урай авылындагы Почта урамы;

Саба районының Яулауташ авылындагы Җәлил урамы;

Саба районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогының Әбрар Кәримуллин урамы;

Саба районының Урта Саба авылындагы Тукай урамы;

Ютазы районының Иске Урыссу авылындагы Чапаев урамы;

Казан шәһәренең Кадышево торак массивындагы «Промстройматериалы» коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәте;

Казан шәһәре Яңа Аракчино торак массивындагы Новостройка урамының 12 номерлы шәхси йорт хуҗалыгы;

Казан шәһәренең Оренбург Тракты урамындагы 128-151 номерлы шәхси йорт хуҗалыклары;

Алексеевск районының Урманасты Шонталысы авылы янындагы «Сөт Иле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте филиалы «Ясная Поляна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең (Шонталы бүлекчәсе) мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Буа районы Кайбыч авылы янындагы «Авангард» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Кайбыч районы Ульянково авылы янындагы «Ак Барс Кайбыч» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең (1 номерлы бригада) мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Питрәч районы Татар Тау Иле авылы янындагы «Ак Барс Питрәч» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше;

Питрәч районы Кибәч авылы янындагы «Золина Е.Н.» крестьян (фермер) хуҗалыгының яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше.

Саба районы Шекше авылы янындагы «Алтын Саба-М» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең яшь терлек асрау өчен файдаланылучы территориясенең бер өлеше.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Кукмара районының Аман-Оштырма авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 6 мартындагы ПУ-249 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 23 мартындагы ПУ-307 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 18 апрелендәге ПУ-392 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 22 июнь
№ ПУ-573

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ